## СҮЗЛЕКНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

1. Сүзлекнең лөгатьлеген төрле тарихи чорларда татар чыганакларында теркәлгән һәм хәзерге чорда кулланыла торган төрки, татар, гарәп, фарсы, рус, европа чыгышлы татар кеше исемнәре тәшкил итә.

2. Сүзлектә ир-ат һәм хатын-кыз исемнәренең норматив вариантлары аерым бүлекләр рәвешендә татар һәм рус телләрендә алфавит тәртибендә бирелә.

3. Сүзлек мәкаләсе түбәндәге зоналардан гыйбарәт:

а) башта калын шрифт белән баш сүз (вокабула) китерелә;

ә) алга таба җәяләр эчедә курсив белән чыганак тел бирелә. Әгәр исем кушма булса, чыганак тел, кагыйдә буларак, һәр өлеш өчен аерым күрсәтелә:

**Сабирҗан** (*гар. – фар.*)
**Сагынбай** (*бор. төрки-тат.*)
**Салихкол** (*гар. – төрки-тат.*)

б) исемнең мәгънәсен аңлату тасвирлап яки мәгънәсе аңлатылган башка исемгә сылтама китерү юлы белән бирелергә мөмкин;

в) исем күпмәгънәле булса, аерым мәгънәләре үзара гарәп цифрлары белән аерыла:

**Мөзәкирә** (*гар.*) 1. Искә төшерүче, зикер кылучы. 2. Үгет-нәсыйхәт бирүче.

г) диалекталь яки башка киң таралган вариантлар булганда, алар аңлатмадан соң килгән *Төрдәшләр* тамгасыннан соң бирелә:

**Хәйбулла** (*гар.*) Алланың яшерен сере, Алла белә торган сер. *Төр.:* Хәйбул, Айбул, Кайбул, Хәйбуш, Кайбуш, Кайбыш, Кайбыч.

д) бинар исем термины белән ир-ат һәм хатын-кыз исемлекләрендә кулланыла торган антропонимнар бирелә:

**Йолдыз** (бор. төрки-тат.) Йолдыз, күк җисеме; йолдыз кебек якты, нурлы, күркәм. Тарихи исем. Борынгы төрки чорда Julduz – Угыз ханның бер улы исеме. Аеруча XX йөзнең 20–30 нчы елларыннан актив кулланыла башлый. Бинар исем.

4. Рус телендәге сүзлек мәкаләсенең структурасы татар өлешендәге сүзлек мәкаләсе структурасын кабатлый.

5. Сүзлеккә кертелмәде:

а) искергән һәм бөтенләй кулланыштан төшеп калган исемнәр;

ә) 1917 елгы Октябрь революциясеннән соң ата-аналарның индивидуаль карары нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм кеше исемнәре системасына кереп китмәгән исемнәр: *Союз, Трактор, Фикус, Марлен, Дипр...*

б) ялгыш язылган вариантлар (диалекталь вариантлары белән бутамаска).